Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25.03.2020 Менделеевск ш. № 214

2020-2022 елларга Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районында
конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча
чаралар планын («Юл картасын») раслау турында

Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 31 августындагы 306 номерлы күрсәтмәсен үтәү турында «2019 - 2022 елларга Татарстан Республикасында конкуренция үсешенә ярдәм итү өчен товар базарлары исемлеген һәм Татарстан Республикасында конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча чаралар планын («юл картасын») раслау турында», Татарстан Республикасында конкуренция үсеше милли планын гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 26 декабрендәге АП-12-397 номерлы беркетмәсе нигезендә. Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 - 2022 елларга Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча чаралар планын («Юл картасын») кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында 2018-2020 елларга конкуренция үсешенә ярдәм итү буенча чаралар планын («Юл картасы») раслау турында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 29 гыйнварындагы 38 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында әлеге карарны бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendelevsk.tatarstan.ru «Норматив документлар» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Житәкче Р.А.Абдуллин

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 25 мартындагы
214 номерлы карарына кушымта

**2020-2022 ЕЛЛАРГА МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА**
**КӨНДӘШЛЕКНЕ ҮСТЕРҮГӘ ЯРДӘМ ИТҮ БУЕНЧА**
**ЧАРАЛАР ПЛАНЫ ("ЮЛ КАРТАСЫ")**
*Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең исеме*

| N п/п | Бурычларны үтәү өчен чараның исеме | Җаваплы башкаручылар һәм төп катнашучылар | Чараны тормышка ашыру вакыты | Максатчан индикаторлар | Күрсәткеч индикаторын исәпләү методикасы | **ИСКӘРМӘ** |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Социаль әһәмиятле базарларда конкуренцияне үстерү** | | | | | | |
| **Балаларга өстәмә белем бирү хезмәтләре базары** | | | | | | |
| 1 | Яшьләр һәм инновация иҗатының белем бирү түгәрәкләрен ачу | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты, «ТР Менделеевск | 2020 - 2022 еллар | Яшьләр һәм инновацион иҗат ачык белем бирү үзәкләре саны<br><br>2020 елда - 1; | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | 2019 ел - 2 балаларга өстәмә белем бирү үзәге (Балалар иҗат үзәге, Ладушки) хосусый |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ | | 2021 елда - 1;<br>2022 елда - 1. | | оешмалар өлеше, %:<br>2019 ел - 50,0<br>2020 ел - 50,0<br>2021 ел - 50,0<br>2022 ел - 50,0 |
| 2 | Балаларга өстәмә белем бирүнең хосусый учреждениеләрен төзүнең, балаларга өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру буенча эшкуарлык эшчәнлеген оештыруның билгеләнгән тәртибе (регламенты) турында эшкуарлык субъектларына мәгълүмат бирүне арттыру | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты, Икътисад, сәнәгать һәм эшкуарлыкка ярдәм бүлеге | 2020-2022 еллар | Рәсми сайтта һәм электрон почта аша мәгълүмат урнаштыру: кварталга 1 тапкыр. | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | |
| **Торак-коммуналь хуҗалык базары** | | | | | | |
| 1 | Торак-коммуналь хуҗалык объектларының нәтиҗәле булмаган идарәне гамәлгә ашыручы барлык дәүләт һәм муниципаль предприятиеләрнең | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты, Менделеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир | 2020 - 2022 еллар | Передача объектов жилищно-коммунального хозяйства на основе концессионных соглашений, единиц:<br><br>2020 елда - 2; | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми. Концессия килешүләре нигезендә хосусый | 14 авыл җирлегендә торак-коммуналь хуҗалык объектлары авыл җирлекләре милкендә. |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | концессион килешүләре нигезендә хосусый операторлар идарәсенә тапшыру | мөнәсәбәтләре палатасы | | 2021 елда - 2;<br>2022 елда - 2. | операторларга тапшырылган нәтиҗәсез идарә итүне гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль предприятиеләрнең торак-коммуналь хуҗалык объектлары саны, идарә итүнең нәтиҗәлелеген анализлау нигезендә актуальләштерелгән графиклар нигезендә, берәмлек; | |
| **Ваклап сату базары** | | | | | | |
| 1 | Кече һәм ерак авыл торак пунктларында яңа сәүдә объектларын ачу | Татарстан Республикасы Менделеевск | 2020 - 2022 еллар | Кече һәм ерак авыл торак пунктларында ачылган сәүдә объектлары саны, | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү | 2019 ел - Кече һәм ерак авылларда сәүдә итүнең 14 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | муниципаль районы башкарма комитеты | | түбәндәге берәмлекләр бар:2020 елда - 1;<br>2021 елда - 1;<br>2022 елда - 1. | методикасы таләп ителми | объекты. Шәхси оешмалар өлеше, %:<br>2019 ел - 100,0<br>2020 ел - 100,0<br>2021 ел - 100,0<br>2022 ел - 100,0 |
| 2 | Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан яңа сәүдә объектларын ачу мөмкинлеген тәэмин итү | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2020 - 2022 еллар | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендә яңа сәүдә объектлары ачылуга кирәкле сан 2020 елда - 1; 2021 елда - 1; 2022 елда - 1. | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | |
| | | | | Кече һәм урта эшкуарлык субъектларыннан яңа сәүдә объектларын ачу турында уңай хәл ителгән гаризалар саны 2020 елда - 1;<br>2021 елда - 1;<br>2022 елда - 1. | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | |
| **Даими пассажирлар йөртү муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында пассажирлар ташу буенча хезмәт күрсәтү базары** | | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Муниципаль һәм муниципальара дәрәҗәдә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2020 - 2022 еллар | Яңа муниципаль һәм муниципальара маршрутларны ачу:<br><br>2020 елда - 0;<br>2021 елда - 1;<br>2022 елда - 1. | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | Транспорт хезмәтен 2 оешма - Менделеевск АТП һәм ИП Салихова башкара. Шәхси оешмалар өлеше, %:<br>2019 ел - 100,0<br>2020 ел - 100,0<br>2021 ел - 100,0<br>2022 ел -  100,0 |
| **Медицина хезмәтләре базары** | | | | | | |
| 1 | Шәхси медицина учреждениеләрен ачу | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты | 2020 - 2022 еллар | Яңа медицина учреждениеләре, берәмлек:<br><br>2020 елда - 1;<br>2021 елда - 0;<br>2022 елда - 0. | Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми | 2019 ел - 6 медицина хезмәтләре күрсәтүче 6 оешма ( МЦРБ, мед. центр Доверие,  мед. кабинет Лориалл, стоматологические клиники Дента, Нурлы, Улыбка) Шәхси оешмалар өлеше, %:<br>2019 ел - 83,3<br>2020 ел - 85,7<br>2021 ел - 85,7<br>2022 ел -  85,7 |

<table>
<tr><th colspan="7">Тышкы реклама өлкәсе базары</th></tr>
<tr><td rowspan="2">1</td><td rowspan="2">Реклама конструкцияләрен урнаштыру өлкәсендә конкуренцияне үстерү</td><td rowspan="2">Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты</td><td rowspan="2">2020 - 2022 еллар</td><td>Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү срогын кимендә 5 елга билгеләү, %<br>2020 елда -100%;<br>2021 елда -100%;<br>2022 елда -100%</td><td>Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми</td><td rowspan="2">Тышкы реклама өлкәсендә хуҗалык итүче субъектларның гомуми санда милек рәвешендәге хуҗалык субъектлары өлеше (%):<br>2020 -100<br>2021 -100<br>2022 -100</td></tr>
<tr><td>Лотларны берләштерүне булдырмау (1 лот - 1 реклама конструкциясе)<br>2020 елда -100%;<br>2021 елда -100%;<br>2022 елда -100%</td><td>Абсолют күрсәткеч. Исәпләү методикасы таләп ителми</td></tr>
</table>